ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 34 25 февраль 2019 ел

## Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиеш мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, карар бирәм:

1. Гражданнарны найм килешүләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган чираттагы максималь керем күләмен билгеләргә:

1.1. Ялгыз кеше өчен – 35 341,74 сум;

1.2. Ике кешелек гаилә өчен – 22 490,20 сум;

1.3. Өч кешелек һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен – 19 277,31 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге җитәкчесе И.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче Д.И. Баландин